**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 март № 148

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «162», «774», «109» һәм «521,4» саннарын тиешенчә «166», «792,6», «113», «540,3» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.1 нче пунктта:

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы булган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен, муниципаль һәм

хосусый оешмаларның (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләреннән тыш) һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү (04.05.09*);

3.3 нче пунктта:

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары катнашында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшли;»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«законнар нигезендә дәүләт ихтыяҗлары һәм билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге Министрлык ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технология эшләрен кертеп, сатып алуны гамәлгә ашыра;»;

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләреннән тыш, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы булган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен, муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләүне оештыра;»;

утыз бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә реализацияләнә торган продукциягә (товарларга) бәяне арттыруның ул билгеләгән иң чик максималь дәрәҗәләрен куллану өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итә;»;

утыз алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләүне оештыру мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган

товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге буенча заказлар урнаштырудан тыш, Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмалар булган заказчылар өчен заказлар урнаштыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора;»;

утыз җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон нигезендә электрон мәйданчык операторына вәкаләтле орган исеменнән эш итәргә хокуклы затның көче арттырылган электрон имзасы куелган, заказчының көче арттырылган электрон имзасы куелган, төзелгән контрактның күчермәсен җибәрә;»;

утыз алтынчы абзацка «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый оешмалар» сүзләреннән соң «физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләреннән тыш;» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен федераль законнар нигезендә шартлар тудыра;

иҗтимагый оешмалар катнашында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет формалаштыра һәм аның турындагы нигезләмәне раслый;

федераль законнар нигезендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатына бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра;

үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гражданнар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфаты турында фикерләрен белдерү өчен техник мөмкинлек тәэмин итә;

юридик затларның документларын карап тикшерә һәм мәгариф һәм тәрбия эше объектларының, Министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясында күрсәтелгән критерийларга, әлеге критерийларның Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган сыйфат һәм (яки) сан күрсәткечләренә туры килүе турында бәяләмәләр проектларын килештерә;

белем бирү оешмалары өчен федераль бюджет акчасы исәбеннән сатып алына торган автобусларны кабул итүне гамәлгә ашыра;

Министрлыкның ведомство буйсынуындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларны һәм Министрлыкның ведомство

буйсынуындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләрен аттестацияләүне оештыра;

террорчылыкка каршы тору чараларын тормышка ашырганда укыту-өйрәтүләр үткәрүдә катнаша;

террорчылыкны профилактикалау, аны үткәрү нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү өлкәсендә чаралар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә катнаша;»;

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.3 нче пункт өстәргә:

«4.3. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

04.05.09 кодлы функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен (физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләреннән тыш) һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков